# Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныф укучыларына ТАТАР ТЕЛЕННӘН бердәм республика тесты

## 0053 нче вариант

## Эшне үтәү өчен күрсәтмә

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының 9 нчы сыйныфын тәмамлаучы укучылар өчен, татар теленнән бердәм республика тестына 2 сәгать 30 минут (150 минут) вакыт бирелә. Тест биремнәре 3 бүлектән тора.

**Беренче бүлек**тә 2 тапкыр **тыңланган** текстның кыскача эчтәлеге (изложение) языла. Ул **2 нче номерлы җавап бланкында** эшләнә.

**Икенче бүлек**не укучылар **үзләре укыган** текстка нигезләнеп башкара. Ул 9 биремнән тора (2-10 биремнәр). 2 – 3 нче биремнәрне үтәгәндә, дөрес җавапны тәкъдим ителгән 4 варианттан сайлап алып, 1 нче номерлы җавап бланкына бер цифр белән язарга кирәк. Бу бланкта 1 нче бирем җавабын язарга тиешле урын буш кала. 4 – 10 нчы биремнәргә җавапларны укучылар мөстәкыйль рәвештә формалаштыралар. Әлеге биремнәргә җаваплар сүз яки цифрлар белән 1 нче номерлы җавап бланкына языла. Ялгышкан очракта, аны пөхтә итеп сызып, янына дөрес җавапны язарга була.

**Өченче бүлектәге** биремне укучылар 2 нче бүлектәге текст буенча башкаралар. Эшли башлаганчы, тәкъдим ителгән (11.1 һәм 11.2) биремнәрнең берсен сайларга һәм үз фикереңне дәлилләп, эзлекле рәвештә киңәйтелгән җавап бирергә кирәк.

Тест биремнәрен үтәгәндә, орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Караламадагы язулар тикшерелми!

Биремнәрне тәкъдим ителгән эзлеклелектә эшләргә киңәш ителә. Җавап бирергә авырсынган бирем очраса, аны калдырып, башкаларын эшли торыгыз. Вакыт калса, аларга яңадан әйләнеп кайтырсыз.

Үтәлгән биремнәр өчен куелган баллар бергә кушыла. Мөмкин кадәр күбрәк биремгә дөрес җавап биреп, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

**Сезгә уңышлар телибез!**

## I бүлек

***Текстны тыңлагыз һәм 1 нче биремне 2 нче номерлы җаваплар бланкында эшләгез. Башта биремнең номерын, аннары изложение текстын языгыз.***

1 Текстны тыңлагыз һәм кыска изложение языгыз. Текстны тыңлагач, микротемаларны билгеләгез. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Изложениенең күләме **50 сүздән** ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

## II бүлек

***Текстны укыгыз һәм 2-10 нчы биремнәрне үтәгез.***

### Чишмәләр

1) Әби-бабаларыбыз заманында чишмәләргә игътибар зур булган. 2) Аерым кешеләр аларны карап торган. 3) Чишмә башларын күз карасыдай саклаганнар. 4) Кеше исемнәре белән аталган чишмәләр аларны мәңгеләштергән.

5) Чишмәләр – барлык төр сулыкларның башлангычы, тукландыра торган чыганаклары. 6) Чишмә яшәүдән туктаса, елга-күлләрдә су бетәчәк, авылда ямь калмаячак. 7) Хәзерге авыллар бай һәм матур. 8) Һәр йорттан диярлек берәр транспорт чыга, ә табигать ярлылана бара. 9) Урамнарда инде чирәм, үлән үсми, авыл эчендәге һәм тирә-юнендәге чишмә чыганакларын чистартып тормагач, алар тилмереп кибәләр.

10) Чишмәләрне халкыбыздагы чисталыкны, сафлыкны күрсәтү өчен чагыштыру итеп кулланалар. 11) Саф һәм пакъ, киң күңелле кеше турында сөйләгәндә, гадәттә, чишмә суы сафлыгы да күздә тотыла.

12) Чишмә-чыганакларны карауга әби-апаларыбыз зур әһәмият биргәннәр. 13) Татарстандагы һәр авылда диярлек берәр хатын-кыз исеме белән аталган чишмә очрамый калмый. 14) Әйтик, Абыстай чишмәләре шактый еш очрый. 15) Зөбәйдә, Канифә чишмәләре, Зәбидә, Сәрия күлләре, Сәлия, Оркыя елгалары шул исемдәге хатын-кыз исемнәрен киләчәк буыннарга истәлек итеп мәңгеләштергәннәр.

16) Соңгы вакытта элек-электән килә торган традиция юкка чыга бара. 17) Техника үскән саен, табигатькә зыян күбрәк килә. 18) Чишмәләрне чистартып, тирә-юненә рәшәткә тотып, кечкенә генә агачлар утыртып була. 19) Тик моның өчен күңел кирәк, туган төбәгеңне ярату кирәк. (*Фирдәвес Гариповадан*)

***Гарипова Фирдәвес Гариф кызы*** *(1941) – тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказан фән эшлеклесе. Хезмәтләре татар топонимикасына (гидронимнарына) карый.*

***2 – 10 нчы биремнәрнең җавабы сүз яки цифр булырга мөмкин. Башта җавапны текстта күрсәтегез, соңыннан 1 нче номерлы бланкка <u>буш ара калдырмыйча, тыныш билгеләрсез, башка өстәмә символларсыз</u> күчереп алыгыз. Һәр хәрефне һәм санны, бланктагы үрнәктә күрсәтелгәнчә, аерым шакмакка языгыз.***

**2** **Сингармонизмга буйсынмаган сүз кулланылган җөмләнең номерын күрсәтегез.**

1) Чишмәләр – барлык төр сулыкларның башлангычы, тукландыра торган чыганаклары.

2) Урамнарда инде чирәм, үлән үсми, авыл эчендәге һәм тирә-юнендәге чишмә чыганакларын чистартып тормагач, алар тилмереп кибәләр.

3) Чишмәләрне, тирә-юненә рәшәткә тотып, кечкенә генә агачлар утыртып кына саклап була.

4) Тик моның өчен күңел кирәк, туган төбәгеңне ярату кирәк.

Җавап:________________.

**3** **Үзара синоним булган сүзләр кулланылган җөмләнең номерын күрсәтегез.**

1) Саф һәм пакъ, киң күңелле кеше турында сөйләгәндә, гадәттә, чишмә суы сафлыгы да күздә тотыла.

2) Татарстандагы һәр авылда диярлек берәр хатын-кыз исеме белән аталган чишмә очрамый калмый.

3) Әйтик, Абыстай чишмәләре шактый еш очрый.

4) Соңгы вакытта элек-электән килә торган традиция юкка чыга бара.

Җавап:________________.

**4** **6-8 нче җөмләләрдән тиңдәш хәбәрләре булган җөмләнең номерын языгыз.**

Җавап: ________________ .

**5** **13-16 нчы җөмләләрнең кайсында юнәлеш килешендәге исем бар?**

Җавап: ________________.

**6** **6-8 нче җөмләләрдән үзара синоним булган сүзләр кергән җөмлә номерын табып языгыз.**

Җавап: ________________ .

**7** **4-6 нчы җөмләләрдән бәйлекне күчереп языгыз.**

Җавап: ________________ .

**8** **16-18 нче җөмләләрдән синтетик иярченле кушма җөмләнең номерын языгыз.**

Җавап: ________________ .

**9** **Түбәндәге җөмләдә барлык тыныш билгеләре номерланган. *Тиңдәш ияләр* арасына куелган тыныш билгесенең номерын языгыз.**

Һәр йорттан диярлек берәр транспорт чыга[1], ә табигать ярлылана бара;[2] урамнарда инде чирәм[3], үлән үсми[4], авыл эчендәге һәм тирә-юнендәге чишмә чыганакларын чистартып тормагач[5], алар тилмереп кибәләр[6].

Җавап: _______________ .

**10** Текст **нинди стильдә** язылган?
Җавап: _______________ .

***Барлык җавапларны, тестны үтәү өчен күрсәтмәдә әйтелгән тәртиптә, 1 нче номерлы бланкка күчереп язарга онытмагыз.***

## III бүлек

***2 нче бүлектә укылган текстны файдаланып, 11.1 һәм 11.2 нче биремнәрнең <u>бары тик берсен генә сайлап алып</u>, 2 нче номерлы бланкта биремне үтәгез. Яза башлар алдыннан сайланган биремнең номерын күрсәтегез.***

**11.1. "Техника үскән саен, табигатькә зыян күбрәк килә. Чишмәләрне чистартып, тирә-юненә рәшәткә тотып, кечкенә генә агачлар утыртып була. Тик моның өчен күңел кирәк, туган төбәгеңне ярату кирәк"** җөмләләрендә әйтелгән фикерләрне сез ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган текстттан **2 мисал** китерегез. Файдаланган җөмләләрнең номерларын языгыз яки текстттан цитата китерегез.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен, ноль балл куела.

**11.2. "Ата-бабам торган җир, кендек каным тамган җир", -** диелә халык мәкалендә. Бу мәкальнең мәгънәсен ничек аңлыйсыз? Шул темага сочинение языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укылган текстттан **1 мисал**, үзегезнең тормыш тәҗрибәсеннән **1 мисал** китерегез.

Сочинениенең күләме **50 сүздән** дә ким булмаска тиеш.

Сочинениене чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Укылган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Бирелгән текстны күчереп яисә аның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган өчен ноль балл куела.